СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЮГАРЫ ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

16.11.2021 с. Верхний Услон № 14-99

Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә, Югары Ослан торак пунктында яшәүчеләрнең инициативасын карап,

Югары Ослан муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2021 нче елның 4 нче декабренә 11 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?:

- Югары Ослан авылы Язгы урамында балалар мәйданчыгы төзү».

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. РФ, ТР, Югары Ослан районы, Югары Ослан авылы, Язгы ур., 15 нче йорт адресы буенча урнашкан торак йорт янында гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Җыенны Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитеты оештыра.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М.Г.Зиатдинов